
# Авыл эте Акбай!



## Туфан Миңнуллин.

**Җырлый-җырлый Нажия**

**Урманда җиләк җыя.**


**Сызганган ул җиңнәрен**

**Җыя кура җиләген.**

# Дуслык турында җыр.

**Ә.Ерикәй сүзләре. С.Сәйдәшев музыкасы.**

Үстергән дә безне чын дуслык,
Көч биргән дә безгә чын дуслык.
Дуслык булса, яшәр гомергә
Бөтен җир шарында тынычлык.





**Туфан Миңнуллин – Г. Афзал исемендәге премия лауреаты, җәмәгать эшлеклесе, драматург.**


# Туфан Миңнуллин –драматург.

Туфан Миннуллин родился в 1935 году в деревне Большое Мереткозино Камско-Устьинского района Татарстана. Окончил Театральное училище имени М.С. Щепкина в Москве. Работал актером в Мензелинском академическом театре. В 1962 году были поставлены первые спектакли, написанные драматургом. Двумя годами позже он работал на Казанской телестудии и в журнале «Чаян». В 1975-1977 годах продолжил образование на Высших литературных курсах в Москве. С 1984 по 1989 год руководил правлением Союза писателей ТАССР.

# Туфан Миңнуллин –драматург.

**Туфан Абдуллович Миннуллин** ушел из жизни **2 мая 2012 года**.

Среди произведений драматурга — пьесы «Альмандар из деревни Альдермеш», «Матери и дети» (1984); «Мы уходим, вы остаетесь» (1986), «Прощайте» (1993), историческая драма «Бахтияр Канкаев» (1974) и многих других. Туфан Миннуллин — лауреат государственной премии РСФСР им.К. Станиславского (1979) и государственной премии им.Г.Тукая (1979).



Татарстанның халык язучысы

# Туфан Миңнуллин

**Туфан Миңнуллин -**

**күренекле драматург, хикәяче, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе**

# Пьесалары

**Айбулат**

**Үзем белән үзем**

**Кайда хаклык, кайда дөреслек?**

**Әниләр һәм бәбиләр**

**Миләүшәнең туган көне**

**Дуслар җыелган җирдә**

**Илгизәр + Вера**

**Әлдермештән Әлмәндәр**

**Туфан Миңнуллин**

**һәм**

**Минтимер Шәймиев**




Туфан Миңнуллин – гаҗәп талант иясе. Берсеннән-берсе оста, талантлы сәхнә әсәрләрен коеп кына куя, коеп кына тора. Ходай аңа оригиналь фикерләү сәләтен, тормышны чагылдыру осталыгын бер дә кызганмый биргән.

*Минтимер Шәймиев, Татарстан Президенты. 1995*

# Спектакльдән фото өзек...





# Спектакльдән фото өзек...









# Спектакльдән фото өзек...












# Видео ролик «Авыл эте Акбай».



# Туфан Миңнуллинның “Авыл эте Акбай” әсәре белән эш.

## Сүзлек эше.

Иркәли- ласкает
Тычкан- мышка
Күсе-крыса
Мәгънәсез-бестолковый
Ышана-верит
Харап-страшно, жутко
Берүзе-один

# *Чөнки* теркәгечен кабанлау.

**Теркәгеч** - җөмлә кисәкләрен һәм кушма җөмләдә гади җөмләләрне бәйли торган бәйләгеч сүз төркеме.

1. Тергәгечләр (союз) нәрсәне бәйләүдә файдалана торган сүз төркеме?
2. Ни өчен  тергәгечләр бәйләгеч сүз төркеменә (словосоедительные части речи) керәләр?
3. Тергәгечләр нинди ике төркемгә бүленәләр?

Бәйләүче чара *чөнки* теркәгече. Ни сәбәпле? Ни өчен?

**Мисал:** Сәфәргали җыргa катнашмады, *чөнки* ул аны белми иде.

Мәче берничә тапкыр балык сорарга килгән, *чөнки* ул ачыккан.

# Аның нишләгәне бар/ юк? грамматик структурасын активлаштыру.

Ул нишләгән? һәм Аның нишләгәне бар? Аның нишләгәне юк? формалары мәгънә һәм кулланыш ягыннан охшаш.

**Мәсәлән:** Русчага тәрҗемә итсәк: Что он/она сделал(а)? һәм Что ему/ей приходилось делать? Что ему/ей не приходилось делать?

Песинең шәһәр турында ишеткәне бар. – Кошке приходилось слышать про город/ Кошка слышала про город.

Этнең шәһәр турында ишеткәне юк. – Собаке не приходилось слышать про город/ Собака не слышала про город.

## Әсәрдә катнашучы төп геройлар белән танышыйк. Рольләрне бүлешеп геройларга телдән характеристика бирегез.

Мәсәлән:

“Минем исеме – ***Тәмлетамак***, иркә авыл песие. Миңа тычкан тотарга кушалар...”

“Мин – ***Акбай***...”

# Әсәрнең сәнгатьчә үзенчәлекле эшләнешенә игътибар итик.

- Әсәр әкиятме, әллә хикәяме?
- Әкияткә хас нинди үзенчәлекләрен әйтә аласыз?
- Пьесамы? Ә ни өчен шулай да әсәрне әкият димибез?
- Эт исемнәренә салынган мәгънә турында уйланыйк.


Мәсәлән, Акбай сафлык, пакьлек, тугрылык, җаваплылык, хезмәт сөю сыйфатларын үзенә туплаган, шуңа күрә Акбай исеме бирелгән. Дәвам итегез...

# Сорауларга җавап эзлик.

- Автор ни өчен йорт хайваннарына этләргә, мәчеләргә мөрәҗәгать итте икән?
- Бу пьесаны тормыш-көнкүреш драмасына кертеп буламы?
- Сезнеңчә, этләрнең кайсын бәхетле язмышлы дип әйтергә мөмкин булыр иде?
- Урам этләре Актүш, Актырнак, Муйнак, Сарбайларның бәхетсезлеген нинди сәбәпләр белән аңлатырга?
- Сарбай үз тормышының кайсы вакытын сагынып искә ала? Ни өчен? Сез аның бәхеткә биргән аңлатмасы белән килешәсезме?
- Акбай Дүрткүзне ни өчен авылга алып кайта? Дүрткүзнең чыннан да озак вакытларга бәхетле булып китәчәгенә ышанасызмы?

# Йомгаклау.

1. Дәрестә нинди язучы турында сөйләштек?
2. Драмматургның нинди әсәре белән таныштыгыз?
3. Әсәр нәрсә турында? Әсәр сезгә ошадымы?
4. Нинди яңалыклар белдегез?



# Өй эше.

Пьесадагы этләрнең язмышына, характер сыйфатларына бәйләп, үз этегез, аларны тәрбияләүгә керткән өлешегез, ирешкән уңышларыгыз турында сөйләгез. Этләрегез белән төшкән фотосурәтләрегезне дә алып килеп күрсәтә аласыз.